**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«9» декабря **2024ел** **№** 155

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 233 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2024 елның 18 октябрендәге 1-31/15348 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 233 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (01.04.2022 № 54, 01.06.2022 № 101, 08.09.2022 № 173, 20.03.2023 № 56, 07.03.2024 № 34, 04.09.2024 № 103 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) күрсәтелгән карарның 1.7 пункты белән расланган Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

1) 2.5.1 пунктның 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле 7.1 пункт белән тулыландырырга:

«7.1) эскроу счетыннан файдаланып төзелеш подряды шартнамәсе турында белешмәләр, мондый шартнамә нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы зат турында белешмәләрне дә кертеп ("Эскроу счетларыннан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында" Федераль закон нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын төзегәндә);»;

2) 3.3.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.1, 3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространстволы күрсәткечләрдән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

3) 3.4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәү вакытыннан алып башкарыла.

Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы күрсәткечләрнең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

4) 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны башкару кысаларында, һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә, ул пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә.»;

5) 3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документның административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат тарафыннан алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат - төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат).

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар белән эшләү буенча ярдәмче системасында һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

- гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документ имзаланган көнне Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре бирү һәм аны алу ысуллары турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү.

Б) күрсәтелгән карарның 1.8 пункты белән расланган, Төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәр итү юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

1) 3.3.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы күрсәткечләрнең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

2) 3.4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәү вакытыннан алып башкарыла.

Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы күрсәткечләрнең милли системасы эшчәнлеген

тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

3) 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны башкару кысаларында, һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә, ул пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә.»;

4) 3.6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документның административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат тарафыннан алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат - төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат).

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар белән эшләү буенча ярдәмче системасында һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

- мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәтне электрон хезмәттәшлек ярдәмендә күрсәтү һәм муниципаль хезмәтне КФҮ күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында Республика порталы аша хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документ имзаланган көнне Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре бирү һәм аны алу ысуллары турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктның А пунктчасының 3 абзацыннан тыш, гамәлдә булган законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин